| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 24 октябрь, 2017 ел | № 20/5 |

Шәһәр Советының 2013 елның 29 агустындагы 26/6 карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2017 елның 18 июлендәге «Россия Федерациясенең Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының кайбер положениеләрен гамәлдән чыккан дип тану турындагы» Федераль законның 3 нче маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» 178-ФЗ санлы Федераль законга нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 29 агустындагы 26/6 Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге 28/7, 2014 елның 16 октябрендәге 33/6, 2015 елның 15 апрелендәге 39/6, 2015 елның 22 октябрендәге 2/14, 2016 елның 24 февралендәге 6/6 Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4 маддәдә:

- 6 өлешне түбәндәге эчтәлектәге 14.1; 14.2 пунктлары белән тулыландырырга:

«14.1) Башкарма комитет билгеләгән очракта, Россия Федерациясе финанс Министрлыгының гомуми таләпләренә туры китереп, Башкарма комитетның финанс органнары раслаган тәртиптә, бюджет акчаларын алу вакәләтләрен үз карамагындагы бюджет акчаларын алучыларга яйсә Башкарма комитетның финанс органына тапшырырга хокуклы;

14.2) Башкарма комитет билгеләгән очракта, Россия Федерациясе финанс Министрлыгының гомуми таләпләренә туры китереп, Башкарма комитетның финанс органнары раслаган тәртиптә төп бүлеп бирүче үз карамагында булган бюджет акчаларын алу вакәләтләрен үз карамагындагы башка бюджет акчалары алучыларга бирергә хокуклы»;

- 12 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә

«12. Бюджет акчаларын алучы түбәндәге бюджет вакәләтләренә ия:

1) бюджет сметасын төзи һәм аны үти

2) билгеләнгән бюджет йөкләмәләре һәм бюджет ассигнованиеләре лимитлары кысаларында бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм (яйсә) башкара;

3) каралган бюджет ассигнованиеләрен тотуның максатчанлыгын һәм нәтиҗәлелеген тәэмин итә;

4) бюджет акчаларын төп бүлеп бирүчегә (бүлеп бирүчегә) бюджет буенча тәкъдимнәр кертә;

5) бюджет хисабын алып бара (бюджет хисабын алып баруны тәэмин итә);

6) бюджет исәп-хисабын ясый (бюджет исәп-хисабын ясауны тәэмин итә) һәм бюджет акчаларын алучының бюджет исәп-хисабын төп бүлеп бирүчегә (бүлеп бирүчегә) тапшыра;

7) Россия Федерациясе финанс Министрлыгы таләпләренә туры китереп, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 158 маддәсе, 3.1 пунктына нигеләнеп Башкарма комитетның финанс органы билгеләгән тәртиптә бюджет акчаларын алучыларга бюджет вакәләтләрен тапшыра;

8) Россия Федерациясе Бюджет кодексы билгеләгән һәм аңа нигезләнеп кабул ителгән муниципаль хокукый атлар нигезендә бюджет өлкәсендә хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка вакәләтләрне башкара.»;

2) 5 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 3.1 өлеше белән тулыландырырга:

«3.1. Эшчәнлек нәтиҗәсендә табыш алучы казна учреждениесе күрсәткн хезмәткә яки башкарган эшкә түләү тертибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.»;

3) 8 маддәдә:

- 6.1 өлешенең 2 пункты, дүртенче абзацында «ирешелмәгән» сүзеннән соң «(муниципаль бирем үтәлмәгән очракта, мөмкин булган (рөхсәт ителгән) тайпылышларны исәпкә алып» сүзләрен өстәргә»;

- түбәндәге эчтәлектәге 6.2 өлешен өстәргә:

«6.2. Муниципаль хезмәтләр (башкарылган эшләр) күләмен характерлаучы муниципаль бирем күрсәткечләренә ирешелмәгән (рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышларны арттырган) очракта, шулай ук мунипаль хезмәтләрнең (башкарылган эшләрнең) сыйфатын билгеләүче һәм биремдә билгеләнгән күрсәткечләргә ирешелмәгән очракта муниципаль бирем үтәлмәгән дип санала.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 9.1 өлешен өстәргә:

«9.1. Бюджет йөкләмәләре лимитын шәһәр бюджеты турындагы карарга туры китерү ниятеннән кире кайтарган очракта, муниципаль заказчылар кабул ителүче бюджет йөкләмәләре күләменнән артмаган һәм Башкарма комитетның финанс органы тарафыннан билгеләнгән күләмдә муниципаль контракт төзергә хокуклы

- 12 өлешнең икенче абзацындагы «78 маддәнең 6 һәм 7 пунктларында» сүзләрен «78 маддәнең 6-7 пунктларында» дип үзгәртәргә;

- 12 маддәнең 4 пунктчасын түбәндәге редекциядә бәян итәргә:

«4) агымдагы финанс елында товар җитештерү (реализацияләү), хезмәт күрсәтү өчен финанс тәэмин ителеше максатында бирелеп, финанс елында тотылмаган субсидия алучыларның субсидиянең калган өлешен кайтару тәртибе һәм очраклары (субсидия алучының акчалата йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле финанс чыганагы булган сумма кысаларындагы субсидияләрдән тыш);»;

- 12 өлештәге тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге маддәнең 12 өлеше, беренче абзацына нигезләнеп субсидияләр биргән очракта, субсидия бирү турындагы һәм андагы йөкләмәләрне үтәү хакындагы килешүгә субсидия алучыларның һәм үзара йөкләмәләрне үтәү хакындагы килешү нигезендә подрядчыларның, сатучыларның, ерым хезмәт күрсәтүчеләрнең һәм эш башкаручыларның (муниципаль унитар предприятиеләр, хуҗалык ширкәтләре, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый өлешләре булган җәмгыятьләр, шулай ук устав (җыелма) капиталына мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр кергән коммерция оешмаларыннан тыш) субсидияләр бирүче төп бюджет акчаларын бүлүче һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм максатын, шартларын үтәүе төп шарт булып тора»;

- түбәндәге эчтәлектәге 14.1 өлешен өстәргә:

«14.1.Бюджет турында карарда акцияләрнең 100 процентына (өлешенә) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге ия булган юридик затларга аларның милке булган капиталь төзелеш объектларына капиталь салулар ашкаруга һәм (яйсә) алар тарафыннан күчемсез милек объектлары сатып алуга, (соңыннан мондый затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә устав капиталын арттыралар), шәһәр бюджетыннан субсидияләр бүлеп бирү өчен бюджет ассигнованиеләре бирү исәпкә алынырга мөмкин.

Әлеге өлешнең беренче абзацына нигезләнеп, шәһәр бюджетыннан субсидия бирү буенча карарлар Башкарма комитет билгеләгән тәртиптә кабул ителә.

Әлеге өлешнең беренче абзацына туры китереп субсидияләр бирү субсидия бирүне башкаручы бюджет акчалары алучы һәм субсидия алучы юридик зат арасындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән килешүгә түбәндәге нигезнамәләр кертелә: алынган акчаларга сату-алу эшләрен дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алу, хезмәт күрсәтү сферасында контракт системасы хакындагы Россия Федерациясенең законнары нигезендә башкару турында нигезнамә, шулай ук, әгәр бюджет акчаларын бируче муниципаль хокукый актлар белән, әлеге өлешнең дүртенче абзацында билгеләнгән тәртиптә, агымдыгы финанс елында субсидия бирү максатларында бу акчаларга ихтыяҗ булмавын билгеләгән очракта, финанс елында тотылып бетмәгән субсидиянең калган өлешен шәһәр бюджетына кире кайтару турында (субсидия алучының акча йөкләмәсе алынган субсидияне финанслау чыганагы булган субсидияләрдән тыш) нигезнамә.

Әлеге өлештә каралаганча субсидияләр бирү тәртибе, аларны бирү вакыты, шартлары һәм үзара килешүләр төзүгә таләпләрне дә кертеп, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

Расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу вакытын озайтучы Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсендәге 1 нче һәм 8 нче пунктларда күрсәтелгән юридик затларга шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында килешү төзү һәм муниципаль-шәхси партнерлык хакында килешү, Яр Чаллы шәһәре исеменнән концессия килешүләре төзү Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә тормышка ашырыла.»;

- 18 өлешнең икенче абзацында: «капиталь төзелеш объектларында» сүзләрен «күрсәтелгән юридик затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларында һәм (яйсә) һәм аларга, күрсәтелгән юридик затларның бүлендек җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталына взнос кертү максатыннан, һәм (яйсә) мондый бүлендек җәмгыятьләре тарафыннан күчемсез милек объектлары сатып алу» дип үзгәртергә;

4) 45 маддәдә:

- 1 өлешнең 6 пунктында: «муниципаль контрактларны» сүзләреннән соң «шулай ук муниципаль контрактлар, күрсәтелгән килешүләрне үтәү максатында төзелгән контрактлар (килешүләр)» сүзләрен өстәргә

- 2 өлешнең икенче абзацын «муниципаль контрактлар» сүзләреннән соң «шулай ук күрсәтелгән муниципаль контрактларны һәм килешүләрне үтәү максатыннан төзелгән контрактлар (килешүләр)» сузләре белән тулыландырырга, «баш бүлеп бирүчеләрне (бүлеп бирүчеләрне)» сүзләрен «баш бүлеп бирүчеләрне (бүлеп бирүчеләрне, алучыларны)» сүзләренә, «бюджет акчалары биргән» сүзләрен «бюджет акчалары бирү турында килешүләр, муниципаль контракт төзегән» сүзләренә алыштырырга».

2. Әлеге Карарның 1 пункт, 3 пунктчасындагы бишенче, алтынчы, сигезенче, тугызынчы абзацлары, 1,2 пунктчалары 2017 елның 19 июленнән соң хасил булган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Әлеге Карарның 1 пункты, 3 пунктчасының икенче-дүртенче, җиденче абзацлары, 4 пунктчасы 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев